КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 5 сентябрь г.Казань № 789

Эш бирүчедә алга таба стажировка үтү шарты белән һөнәри укытуда булу яки өстәмә һөнәри белем алу чарасын тормышка ашыруга социаль контракт төзегән гражданнарның стажировкасын үткәрү чыгымнарын каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Эш бирүчедә алга таба стажировка үтү шарты белән һөнәри укытуда булу яки өстәмә һөнәри белем алу чарасын тормышка ашыруга социаль контрактларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Эш бирүчедә алга таба стажировка үтү шарты белән һөнәри укытуда булу яки өстәмә һөнәри белем алу чарасын тормышка ашыруга социаль контракт төзегән гражданнарның стажировкасын үткәрү чыгымнарын каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар белән расланган Эш бирүчедә алга таба стажировка үтү шарты белән һөнәри укытуда булу яки өстәмә һөнәри белем алу чарасын тормышка ашыруга социаль контракт төзегән гражданнарның стажировкасын үткәрү чыгымнарын каплау өчен эш бирүчегә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен куллану буенча аңлатма бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин